ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2021ел № 5483

Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибен, махсус билгеләнгән урыннар һәм биналар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 296 статьясының 1 пункты, «Россия Федерациясе сенаторы статусы турында һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутуты статусы турында» 1994 елның 8 маендагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Президентын сайлаулар турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 19-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2014 елның 22 февралендәге 20-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа короновирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Раcларга:

1) теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибен 1 нче кушымтада каралганча;

2) теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар исемлеген 2 нче кушымтада каралганча;

3) теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен түләүсез нигездә бирелә торган биналар исемлеген 3 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2017 елның 6 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 91 нче санында бастырып чыгарылган «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе, махсус билгеләнгән урыннар һәм биналар исемлеге турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 7300 номерлы;

2) 2021 елның 18 июнендә «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) һәм 2021 елның 18 июнендә «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарының 44 нче саннарында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе, махсус билгеләнгән урыннар һәм биналар исемлеге турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 7300 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 15 июнендәге 4012 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (htpps://pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5483 номерлы карарына
1 нче кушымта

Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның
сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү
тәртибе

1. Әлеге тәртип теркәлгән кандидатларның яки депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү процедурасын билгели һәм «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депututы статусы турында» 1994 елның 8 маендагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Президентын сайлаулар турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 19-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2014 елның 22 февралендәге 20-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа короновирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмә нигезендә эшләнде.

2. Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән җәмәгать чаралары рәвешендәге очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

3. Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен, исемлеге Башкарма комитетның әлеге карарының 3 нче кушымтасында күрсәтелгән биналар (алга таба – бина) бирелә.

4. Теркәлгән кандидат яки депутат, сайлаучылар белән очрашу (алга таба – чара) үткәрү датасына кадәр ун эш көненнән дә соңга калмый, бина (алга таба – учреждение) аның оператив идарәсендә булган учреждение җитәкчесенә чара үткәрү турында язмача гариза җибәрә. Гаризада чараның датасы, башлану һәм тәмамлану вакыты, чарада катнашучыларның күздә тотылган саны, чараны үткәрү өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә телефоны, шулай ук бина бирү турында теркәлгән кандидатка яки депутатка хәбәр итү ысулы (үз кулына тапшыру, почта аша җибәрү, телеграмма, факсимиль элемтә, электрон почта аша, электрон документлар әйләнеше юлы белән) күрсәтелә.

Учреждение җитәкчесенә гариза теләсә кайсы уңайлы ысул белән (үз кулына тапшыру, почта аша җибәрү, телеграмма, факсимиль элемтә, электрон почта аша, электрон документлар әйләнеше юлы белән) җибәрелә.

5. Бина түбәндәге шартлар үтәлгән очракта бирелә:

1) чараның башлану вакыты җирле вакыт буенча агымдагы көнне 07.00 сгатьтән соң планлаштырылганда, чараның тәмамлану вакыты 22.00 сәгатькә кадәр планлаштырылганда;

2) чарада катнашучыларның планлаштырылган саны бинаның иң чик сыйдырышлыгының түбәндәге нормаларыннан артмаганда:

- чараны үткәрү урынында стационар тамашачы урыннары белән җиһазландырылган бинаның иң чик сыйдырышлыгы – стационар тамашачы урыннары санынннан артык түгел;

- чараны үткәрү урынында стационар тамашачы урыннары белән җиһазландырылмаган бинаның иң чик сыйдырышлыгы – 4 кв. метрга бер кешедән артык түгел, әмма бер бинада 100 кешедән артык түгел.

6. Гариза, кергән корреспонденцияне учреждениедә теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә, аны алган көнне теркәлә.

8. Теркәлгән гариза ул кергән көнне учреждение җитәкчесенә яисә аның вазыйфаларын башкаручыга тапшырыла.

9. Учреждение җитәкчесе яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат гариза кергән көнне аны карап тикшерә, планлаштырылган чара датасына кадәр кимендә җиде көн алдан Россия Кулланучылар күзәтчелеге идарәсенә язмача белдерү кәгазе җибәрә һәм чара үткәрү килештерелгәндә, гаризада күрсәтелгән көнне һәм вакытта бина бирү турында приказ (боерык) чыгара (әлеге тәртипнең 12 пунктында күздә тотылган очраклардан тыш), чара үткәрү өчен бина бирүне тәэмин итүгә җаваплы затны билгели.

10. Күрсәтелгән приказ (боерык) учреждение җитәкчесе, аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзаланганнан соң бер эш көне эчендә теркәлгән кандидатка яки депутатка һәм бинаның урнашу урыны буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органына җибәрелә.

11. Оешмага 14 сәгатьтән соң кергән гариза, ул кергән көннән соң килүче эш көне тәмамланганчы карап тикшерелә.

12. Түбәндәге очракларда учреждение җитәкчесе яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат әлеге тәртипнең 9-11 пунктларында каралган срокларда, сәбәбен, төгәл датасын һәм вакытын күрсәтеп, чараны башка вакытта үткәрү турындагы тәкъдимне теркәлгән кандидатка яки депутатка җибәрә:

1) гаризада күрсәтелгән датага һәм вакытка бинаның торышын чара үткәрү өчен яраклы хәлгә китерү мөмкин булмаган очракта, бинаның канәгатьләнмәслек техник торышы (биналарның һәм корылмаларның җимерелү куркынычын яки чарада катнашучылар иминлегенә башка куркыныч тудыручы);

2) әгәр бина гаризада күрсәтелгән датада һәм вакытта чара үткәрү өчен башка теркәлгән кандидатка яки депутатка (теркәлгән кандидатларга яки депутатларга) бирелгән булса;

3) әгәр учреждение җитәкчесенең гариза алганчы чыккан боерыгы буенча бинада башка чара үткәрү планлаштырылган булса;

4) гаризада күрсәтелгән чара үткәрү шартлары әлеге тәртипнең 5 пунктында күздә тотылган шартларга туры килмәгән очракта, әлеге тәртипнең 9-11 пунктларында каралган срокларда учреждение җитәкчесе чараны гаризада

күрсәтелгән вакытта югарыда күрсәтелгән шартларны үтәп үткәрү, ә әлеге пунктның 2-4 пунктчаларында күздә тотылган очракларда, чараны төгәл датасы һәм вакыты күрсәтелгән башка вакытта үткәрү турындагы тәкъдимне теркәлгән кандидатка яки депутатка җибәрә.

Учреждение җитәкчесе тарафыннан теркәлгән кандидатка яки депутатка тәкъдим ителә торган чара үткәрү вакыты, әлеге пунктта күздә тотылган чара үткәрүгә комачаулаучы кимчелекләр бетерелгәннән соң, бер сәгатьтән артмаска тиеш. Күрсәтелгән кимчелекләрне 21.00 сәгатьтән иртәрәк бетерү мөмкин булмаган очракта, учреждение җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителә торган чара үткәрү вакыты, әлеге пунктта күздә тотылган чара үткәрүгә комачаулаучы кимчелекләр бетерелгән көннән соң икенче көнне 07:00 сәгатьтән дә соң булырга тиеш түгел.

13. Теркәлгән кандидат яки депутат чараны үткәрү датасына кадәр кимендә ике көн алдан, әлеге тәртипнең 4 пунктында күздә тотылган ысулларның берсеннән файдаланып, чараны әлеге тәртипнең 12 пункты нигезендә тәкъдим ителгән датада һәм (яки) вакытта үткәрергә ризалыгы (риза булмавы) турында учреждение җитәкчесенә хәбәр итә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5483 номерлы карарына
2 нче кушымта

Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар исемлеге

| № т/б | Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның сайлаучылар белән очрашулар үткәрү урыннары |
|---|---|
| | Үзәк районы |
| 1 | Яр Чаллы шәһәре, Энтузиастлар бульвары<br>(Энтузиастлар бульвары, 9 нчы йорт (3/07) адресы буенча административ бина каршында) |
| 2 | Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге сквер (һәйкәл каршындагы мәйданчык) |
| 3 | Яр Чаллы шәһәре, Гренада паркы (Экстрим-парк янында) |
| | Комсомол районы |
| 4 | Яр Чаллы шәһәре, «Сидоровка» паркы<br>(төп фасад яклап С-4б торак йорты каршындагы баскетбол мәйданчыгы янында) |
| 5 | Яр Чаллы шәһәре, Дан аллеясы<br>(ГЭС, 1/8 һәм 1/6 торак йортлар ишегалдында сәхнә һәм спорт мәйданчыгы районында) |
| 6 | Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе<br>(«Тәүбә» мәчете районындагы сәхнә янында) |
| 7 | Яр Чаллы шәһәре, Кыңгыраулы күпер янындагы мәйданчык<br>(Мәләкәс елгасы ярындагы автомобильләр кую урыны янәшәсендә) |
| 8 | Яр Чаллы шәһәре, С.П. Титов исемендәге сквер<br>(ЗЯБ, 17А/01 торак йорт районындагы С.П. Титов бюсты янында) |
| 9 | Яр Чаллы шәһәре, Әкиятләр аллеясы<br>(ЗЯБ, 17/24 торак ишегалдындагы сәхнә янында) |

| | |
|---|---|
| Автозавод районы | |
| 10 | Яр Чаллы шәһәре, «Орган залы» МАМУ каршындагы мәйданчык<br>(концерт залы каршындагы мәйданчык) |
| 11 | Яр Чаллы шәһәре, Җиңү паркы<br>(Җиңү паркы стеласы янындагы мәйданчык) |
| 12 | Яр Чаллы шәһәре, Боровецкий бульвары<br>(50 комплекс, «Чаллы икмәге» СҮ һәм «Новоборовецкое» СҮ арасындагы мәйданчык) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5483номерлы карарына
3 нче кушымта

Теркәлгән кандидатларның яки депутатларның
сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен түләүсез нигездә бирелә торган
биналар исемлеге

| № т/б | Учреждениенең исеме | Адрес | Учреждение җитәкчесе | Залның сыйдырышлыгы (урыннар саны) | Вакыт |
|---|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | | |
| 1 | Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 59 йорт | Ковальчук Гөлчәчәк Хак кызы 39-94-85 | 100 | учреждение белән килешү буенча |
| Комсомол районы | | | | | |
| 2 | Яр Чаллы шәһәренең «15 нче балалар иҗат йорты» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Столбовая урамы, 53 йорт | Грачева Светлана Николаевна 71-25-20 | 100 | учреждение белән килешү буенча |
| 3 | Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Чулман проспекты, 6 йорт | Галиева Ландыш Фирдәвис кызы 36-75-26 | 150 | учреждение белән килешү буенча |
| Автозавод районы | | | | | |
| 4 | Яр Чаллы шәһәренең «КАМАЗ» мәдәният сарае» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 87/22 йорт | Динушова Динара Рәфыйк кызы 54-34-45 | 168 | учреждение белән килешү буенча |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тенистая урамы, 1 йорт | Галиева Ландыш Фирдәвис кызы 36-75-26 | 300 | учреждение белән килешү буенча |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева